**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 7 август № 573

г. Казань

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар булдырырга.
2. Теркәлгән Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмәне расларга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\573.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 7 август, 573 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү тәртибен билгели.

2. Грантлар бирүнең максаты - Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау, үстерү һәм куллану өчен шартлар тудыру, шул исәптән Татарстан Республикасында үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмалар башлангычлары кысаларында.

3. Грантлар бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) чараларын тормышка ашыруга тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре кысаларында гамәлгә ашырыла.

4. Дәүләт программасы нигезендә, бу максатларга бүленә торган акча чикләрендә ике грант күләме 250 000 (ике йөз илле мең) сум тәшкил итә.

5. Конкурс комиссиясе грантлар алырга теләүчеләрнең проектларын (программаларын), заявкаларын һәм конкурс материалларын карап тикшерә һәм «Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү өчен» номинациясендә грантлар бирү турында карар кабул итә.

6. Грантларны алучылар конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

## II. Төп төшенчәләр

7. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр файдаланыла:

грантлар – субсидияләр рәвешендә бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы (алга таба – Грантлар);

грант бирүче – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы - Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан грантлар бирү вәкаләте бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба – Вәкаләтле орган);

конкурс – Грантлар бирү өчен иҗтимагый оешмалар сайлап алу белән бәйле чара (алга таба – Конкурс);

Конкурста катнашучылар – Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләре гамәлдә булу тармагын саклау, үстерү һәм киңәйтү өлкәсендә проектларны (программаларны) тормышка ашыручы иҗтимагый оешмалар;

конкурс комиссиясе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 28 февраль, 389-б боерыгы нигезендә төзелгән Дәүләт программасын тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – Комиссия);

грант алучылар – Конкурс җиңүчеләре дип танылган, Вәкаләтле орган белән Грант алуга килешү төзегән иҗтимагый оешмалар (алга таба – Грант алучылар).

## III. Төп максатлар

8. Грантлар бирүнең төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру;

гражданнар җәмгыяте институтларын үстерүдә иҗтимагый оешмаларның ролен күтәрү;

иҗтимагый әһәмиятле проектларны (программаларны) тормышка ашыруда иҗтимагый оешмаларның катнашуын активлаштыру;

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләре гамәлдә булу тармагын үстерү һәм киңәйтү өчен шартлар тудыру.

## IV. Конкурста катнашу хокукы

9. Законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Конкурс игълан ителгән көнгә кадәр кимендә бер ел Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашырган иҗтимагый оешмаларга Конкурста катнашырга рөхсәт ителә.

10. Иҗтимагый оешмалар Конкурска бер генә проект (программа) тапшыра.

11. Иҗтимагый оешмалар конкурс нигезендә сайлап алуда 2 елга 1 тапкыр катнашырга хокуклы.

## V. Конкурсны үткәрү тәртибе

12. Конкурсны үткәрү шартлары һәм сроклары турында мәгълүмат Комиссия тарафыннан Конкурс үткәрү турында карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында (алга таба – Сайт) урнаштырыла.

13. Конкурста катнашу өчен иҗтимагый оешмалар түбәндәге документларны тапшыралар:

а) әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча заявканы;

б) дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен;

в) уставның, Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда, оешма мөһере һәм җитәкче имзасы белән расланган күчермәсен;

г) Конкурста катнашуга заявкалар кабул итү вакыты башланганга кадәр иң күбе өч ай алдан бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә күчермәсен;

д) әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча проект (программа) тасвирламасын;

ж) тапшырылган документлар исемлеген.

Иҗтимагый оешмалар Нигезләмәнең әлеге пунктындагы «б» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаганда, Вәкаләтле орган күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә соратып ала.

Проектны тормышка ашыруга чыгымнарның гомуми суммасыннан 20 проценттан ким булмаган күләмен бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән финанслау буенча иҗтимагый оешмалар йөкләмәсе грантлар бирү өчен шарт булып тора.

14. Документлар кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларында тапшырыла яки 420111, Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 йорт адресы буенча җибәрелә, E-mail: mon@tatar.ru.

15. Документларны кабул итү Сайтта Конкурс үткәрелү турында мәгълүмат урнаштырылган көннән соң ун көн эчендә гамәлгә ашырыла.

16. Әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү һәм теркәү Вәкаләтле орган тарафыннан алар кергән көндә башкарыла.

17. Әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән документлар аларны тапшыру вакыты тәмамланган көннән соң өч көн эчендә Комиссия тарафыннан карап тикшерелә.

18. Әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган иҗтимагый оешмаларга Конкурста катнашырга рөхсәт ителә.

19. Иҗтимагый оешмага Конкурста катнашырга рөхсәт итмәү турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы булмаган күләмдә тапшыру, Нигезләмәнең 13 пунктындагы «б» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш;

б) әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән таләпләргә документларның туры килмәве;

в) Конкурска документлар тапшыру вакыты тәмамланганнан соң документлар тапшыру;

г) иҗтимагый оешманың әлеге Нигезләмәнең 9 һәм 11 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

20. Конкурста катнашу рөхсәт ителгән иҗтимагый оешмалар исемлеге һәм Конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән иҗтимагый оешмалар исемлеге Комиссия

утырышы үткәрелгән көннән соң бер эш көне эчендә Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы документлар кабул итү вакыты тәмамланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә үткәрелә.

21. Комиссия утырышы беркетмәсен раслаганнан соң, Конкурста катнашучылар исемлеге, шулай ук Конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән иҗтимагый оешмалар исемлеге эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә Сайтта урнаштырыла.

22. Конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән иҗтимагый оешмаларга мәгълүмат бирү беркетмә расланган көннән соң өч көн эчендә белдерү кәгазе җибәрү юлы белән Комиссиянең җаваплы секретары тарафыннан өстәмә рәвештә башкарыла.

23. Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерияләре әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча билгеләнә.

24. Конкурста катнашучыларның заявкалары Комиссия утырышын үткәргәннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә Комиссия әгъзаларына карап тикшерү өчен тапшырыла. Комиссия әгъзалары үзләренә заявкалар тапшырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ун көн эчендә заявкаларны, аларга теркәлгән документларны карап тикшерәләр һәм бәяләү кәгазьләрен Вәкаләтле органга тапшыралар.

Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү нәтиҗәләре буенча өч көн эчендә рейтинг төзелә.

25. Конкурс җиңүчеләрен сайлап алу процедурасы Комиссия утырышында рейтинг нәтиҗәләре буенча Комиссия әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Комиссия әгъзаларының яртысы катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы санала.

26. Утырыш барышында Комиссия Конкурс җиңүчеләре исемлеген билгели һәм Грантлар бирү турында карар кабул итә.

27. Комиссия утырышы беркетмәсе Комиссия утырышын үткәргән көннән соң бер эш көне эчендә рәсмиләштерелә, Комиссия рәисе яисә утырышта рәислек иткән аның урынбасары һәм Комиссиянең җаваплы секретары тарафыннан имзалана.

28. Конкурс нәтиҗәләре хакында мәгълүмат Конкурс җиңүчеләре исемлеген раслаган көннән соң өч көн эчендә Сайтта урнаштырыла.

## VI. Грантлар бирү тәртибе

29. Грантлар Дәүләт программасы чараларын тормышка ашыруга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованияләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында бирелә.

30. Грантлар бирү турында Комиссия карары Вәкаләтле орган һәм Конкурс җиңүчесе – Грант алучы арасында килешү (алга таба – Килешү) төзү өчен нигез булып тора.

31. Килешү Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат Сайтта урнаштырылган көннән соң ун көн эчендә төзелә.

32. Килешүнең формасы Вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

33. Килешүдә Грантның зурлыгы, аның максатчан билгеләнеше, хисап финанс елында Грантның файдаланылмаган өлешен агымдагы финанс елында Грант алучы

тарафыннан кире кайтару тәртибе, Грантны файдалану турында хисап бирү тәртибе, Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Грант алучының Грант бирелү шартлары, максатын һәм тәртибен саклавын тикшерүләргә ризалыгы, Грант алучы тарафыннан әлеге Нигезләмә һәм төзелә торган Килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр карала.

34. Вәкаләтле орган Килешү төзелгәннән соң җиде көн эчендә Грантны Грант алучының исәп-хисап счетына күчерә.

35. Грант алучы Вәкаләтле орган раслаган форма буенча һәм Килешүдә каралган тәртиптә Вәкаләтле органга Грантны куллану турында хисап бирә.

## VII. Грант алучының җаваплылыгы

36. Грант алучы Вәкаләтле органга тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен гамәлдәге законнар нигезендә җавап тота.

37. Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң утыз көн эчендә Грант алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

38. Грант түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

а) Грант алучы Грантны бирү шартларын үтәмәгәндә;

б) Грант максатчан файдаланылмаганда.

39. Грант алучы әлеге Нигезләмәнең 38 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча Грантны кире кайтару вакытын бозганда Вәкаләтле орган әлеге Нигезләмәнең 37 пунктында билгеләнгән вакыт узган мизгелдән соң җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

40. Күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарылган очракта акча гамәлдәге законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

41. Грантның хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше Килешүдә каралган очракларда Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

42. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы законнарда билгеләнгән тәртиптә Грантны бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

43. Грантны максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлдәге законнар нигезендә вәкаләтле орган тормышка ашыра.

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирүгә конкурста катнашуга**
**заявка**

1. Гариза бирүче оешма исеме һәм адресы, ИНН

____________________________________________________________________________

Адрес:________________________________________________________________
(индекс) (юридик адрес) (фактик адрес)

________________________________
(телефон) (факс) (E-mail)

2. Оешма җитәкчесе

Ф.И.Ат.ис.:__________________________________
Тел.:__________________________________

Адрес:__________________________________________________________________

E-mail: ________________________________________________________________

3. Проект (программа) турында мәгълүмат:

Исеме: _____________________________________________________________

Юнәлеше: __________________________________________________________

Авторы: ______________________________________________________________

Элемтә өчен мәгълүмат_________________________________________________

4. Сез кайчан булса да дәүләт яки муниципаль грант алдыгызмы? Әгәр алсагыз, елын, проект исемен һәм грант суммасын күрсәтегез:

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

5. Проектның (программаның) кыскача тасвирламасы (проектның төп бүлекләре эчтәлеген кыскача бәян итегез)

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

6. Түләү реквизитлары

Банк исеме: ____________________________________________________________
адресы:
______________________________________________________________________________
и-х/с:
______________________________________________________________________________

Заявкада бирелгән бөтен мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар дөрес һәм ышанычлы дип белдерәм, һәм вәкаләтле органның бездән һәм дәүләт һәм муниципаль органнардан тапшырылган белешмәләрне тәгаенләүче мәгълүматны соратып алу хокукын раслыйм.

Җитәкче Ф.И.Ат.ис. ________________________________/_____________/
(имза)
М.У.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә каршы түгел.

Җитәкче Ф.И.Ат.и. __________________________________/______________/
(имза)
М.У.
Дата:

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирүгә конкурста катнашуга проект (программа) тасвирламасы**

(5 биттән артык түгел)

1. Проектны (программаны) тормышка ашыра башлау вакытына торышка гомуми бәяләмә (1 биттән артык түгел):

| |
|---|
| |

2. Проектның (программаның) максатлары һәм бурычлары:

| |
|---|
| |

3. Чаралар планы (төп чаралар тасвирламасы, проектны (программаны) тормышка ашыру этаплары һәм сроклары):

| Т/с | Тормышка ашыру этабы | Чаралар исеме | Тормышка ашыру сроклары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

4. Проектның (программаның) кирәклеген нигезләү:

| |
|---|
| |

5. Проектның (программаның) бюджеты (күздә тотылган керемнәр һәм планлаштырылган чыгымнар сметасы, аны нигезләү):

Чыгымнарның гомуми суммасы (сум):

Грант күләме (сум):
Күздә тотылган бергәләп финанслау суммасы (сум):

(сумнарда)

| Т/с | Чыгымнар исеме | Үз акчасы | Соратылган акча | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| Барысы | | | | |

6. Проектны (программаны) тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәсе:

| Т/с | Нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Күрсәткеч мәгънәсе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Кушымталар CD, DVD-йөртүчеләрдә, электрон һәм басма төрләрдә (видеоматериаллар, фотографияләр, басма продукция һ.б.) тапшырыла.

Җитәкче Ф.И.Ат.и. ______________________________/______________________/
(имза)

М.У.

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

**Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерияләре**

| Т/с | Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерияләре | Бәя (баллар) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Икътисадый нәтиҗәлелек критерияләре | |
| 1.1. | Проектны (программаны) тормышка ашыруга планлаштырылган чыгымнар һәм аның көтелгән нәтиҗәләре чагыштырмасы | Баллар саны тапшырылган проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дән 10 га кадәр |
| 1.2. | Проектны (программаны) тормышка ашыруга чыгымнарның дәлилле булуы | Баллар саны тапшырылган проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дән 10 га кадәр |
| 1.3 | Проектны (программаны) тормышка ашыруга бюджеттан тыш чыганаклардан күздә тотылган керемнәр күләме, акчаны кертеп, бүтән мөлкәт, мөлкәт хокуклары, түләүсез башкарыла торган эшләр һәм күрсәтелә торган хезмәтләр, үз ихтыярлары белән эшләүчеләр хезмәте (проектны (программаны) тормышка ашыруга чыгымнарың гомуми суммасының 20 процентыннан да ким түгел) | Баллар саны тапшырылган проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дән 10 га кадәр |
| 2. | Социаль нәтиҗәлелек критерияләре | |
| 2.1. | Проектны тормышка ашыруның нәтиҗәлелек күрсәткечләре булу, | Баллар саны тапшырылган проектны (программаны), конкурста катнашуга |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | аларның проект (программа) бурычларына туры килүе | заявканың бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дән 10 га кадәр |
| 2.2. | Планлаштырылган чараларның проектны (программаны) тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләргә туры килүе | Баллар саны тапшырылган проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дән 10 га кадәр |
| 3. | Өстәмә критерияләр | |
| 3.1. | Иҗтимагый оешманың проектны (программаны) тормышка ашыру өчен кирәкле матди-техник базасы һәм урыннары булу | Баллар саны тапшырылган проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дән 10 га кадәр |
| 3.2. | Иҗтимагый оешманың проектны (программаны) тормышка ашыру өчен кирәкле кадрлар ресурслары булу | Баллар саны тапшырылган проектны (программаны), конкурста катнашуга заявканың бүтән документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан билгеләнә – 0 дән 10 га кадәр |